ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«25» декабря 2023 ел № 394

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының кайбер карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, шулай ук хокукый ихтыяҗ булмауга бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының кайбер карарларын үз көчләрен югалткан дип танырга:

- "Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы башкарма комитетының 03.03.2017 елның 88 номерлы карары белән расланган «Уңайлы шәһәр мохитен формалаштыру» өстенлекле проектын гамәлгә ашыруны тәэмин итү буенча Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы иҗтимагый комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында» 17.02.2021 елның 41 номерлы;
- «Уңайлы шәһәр мохитен формалаштыру» проектын гамәлгә ашыру буенча Әгерҗе муниципаль районы иҗтимагый комиссиясенең яңа составын раслау турында» 16.08.2019 елның 327 номерлы;
- «2018-2022 елларга Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы территориясендә заманча уңайлы шәһәр мохите формалаштыру» муниципаль программасын раслау турында» 01.03.2018 елның 99 номерлы;
- «Уңайлы шәһәр мохите формалаштыру» проектын гамәлгә ашыру буенча Әгерҗе муниципаль районы иҗтимагый комиссиясен төзү турында» 03.03.2017 елның 88 номерлы.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга, Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында урнаштырырга (http://agryz.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.М. Латыйповка йөкләргә.

**Җитәкчесе** **И.Х. Салихов**